**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылында гражданнар җыены карары**

29 октябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2021 елда Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукы булган балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- артезиан скважинасы һәм суүткәргечнең запас өлешләрен алу һәм урнаштыру, Яңа Кужак авылында юлларны төзекләндерү эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы _________Д.Д. Абдрахманова

Халык җыены секретаре _________ М.Г. Йосыпова